Татарстан Республикасы Законы

**Татарстан Республикасында инвестицияле**
**салым кредиты турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 15 сентябрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның хокукый җайга салу предметы**

Әлеге Закон Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлеше нигезендә Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты бирүнең нигезләрен һәм шартларын билгели, шулай ук Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты бирү турында карар кабул итәргә вәкаләтле органны билгели.

2 статья. **Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты бирелә торган салымнарның төрләре**

Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты түбәндәгеләргә бирелә:

1) Татарстан Республикасы бюджетына күчерү өчен билгеләнгән салым ставкасы буенча оешмалар табышына салым буенча;

2) региональ салымнар буенча:

а) оешмалар мөлкәтенә салымга;

б) транспорт салымына.

3 статья. **Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредитын бирү тәртибе**

Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендә билгеләнгән тәртиптә бирелә.

4 статья. **Региональ салымнар буенча Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты бирү нигезләре һәм шартлары**

1. Региональ салымнар буенча инвестицияле салым кредиты салым органнарында исәптә торучы һәм Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмага түбәндәге нигезләр буенча бирелергә мөмкин:

1) Россия Федерациясе Салым кодексының 67 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән нигезләрнең берсе булганда;

2) яңа производство төзүне һәм (яисә) гамәлдәге производствоны яңадан торгызуны (киңәйтүне, реконструкцияләүне, техник яктан яңадан коралландыруны) башкарганда.

2. Инвестицияле салым кредиты алу өчен нигезләр оешма тарафыннан документаль расланырга тиеш.

3. Инвестицияле салым кредиты бер елдан алып җиде елга кадәр срокка бирелә.

4. Инвестицияле салым кредитыннан файдаланган өчен процент ставкасы инвестиция салым кредиты турындагы шартнамә төзелгән вакытка Россия Федерациясе Үзәк банкының гамәлдәге рефинанслау ставкасының икедән бере күләмендә билгеләнә.

5. Инвестицияле салым кредиты бирү турында карар оешма инвестицияле салым кредиты буенча бурычларын, шул исәптән инвестицияле салым кредитыннан файдаланган өчен процентларны каплау өчен җитәрлек тәэмин итү шарты белән кабул ителә.

Инвестицияле салым кредитын кире кайтару йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү алымнары мөлкәт залогы йә поручительлек булырга мөмкин.

Россия Федерациясе Салым кодексының 73 статьясында каралган тәртиптә тапшырыла торган залог предметы булып торучы мөлкәткә карата оешма тарафыннан мөлкәт иминияте шартнамәсе төзелә. Мөлкәт иминияте шартнамәсенең гамәлдә булу срогы инвестицияле салым кредиты турындагы шартнамәнең гамәлдә булу срогыннан ким була алмый.

6. Инвестицияле салым кредиты бирү турында карар оешманың Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлары булмаганда кабул ителә.

7. Инвестицияле салым кредиты бирүгә юнәлдерелгән акчалар күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы закон белән билгеләнә.

5 статья. **Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты бирү турында карар кабул итәргә вәкаләтле орган**

1. Оешмага әлеге Законның 2 статьясында күрсәтелгән салымнар буенча инвестицияле салым кредиты бирү турында карар, Татарстан Республикасы финанс органы белән килешенеп, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең

инвестиция эшчәнлегенә дәүләт ярдәмен җайга салу һәм бирү өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан кабул ителә.

2. Инвестицияле салым кредиты бирү турындагы карарны килештерү һәм кабул итү тәртибе, шулай ук мондый карарны кабул итү өчен кирәкле документлар исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

6 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон 2012 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 10 октябре
№ 68-ТРЗ